| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>КУДАШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>КОДАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.01.2024 Кодаш авылы № 1

2024 елга вафат булганнарны күмү буенча гарантияләнгән хезмәтләр күрсәтүнең исемлеге бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Күмү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2024 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» 23.01.2024 елның 46 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Расларга:

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлегендә, якын туганнары, хатыны(ире), законлы вәкиле булган вафат булганнарны күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең 2024 елга гарантияләнгән исемлеге бәясе (1 нче кушымта);

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлегендә, якын туганнары, хатыны(ире), законлы вәкиле булмаган вафат булганнарны күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең 2024 елга гарантияләнгән исемлеге бәясе (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның гамәлләре 01.02.2024 елдан барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкчесе Ф.М.ШАКИРОВ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге Башкарма комитетының 31.01.2024 елның 1 номерлы карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлегендә, якын туганнары, хатыны(ире), законлы вәкиле булган вафат булганнарны күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең 2024 елга гарантияләнгән исемлеге бәясе**

| **Т/с** | **Хезмәт күрсәтүнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүнең бәясе** ***(сум)*** |
|---|---|---|
| 1. | Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. | Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3584,40 |
| 3. | Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 879,74 |
| 4. | Күмү (кабер казу һәм җирләү) | 3906,06 |
| | **Барлыгы** | **8370,20** |

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Кодаш авыл
җирлеге Башкарма комитетының
31.01.2024 елның 1 номерлы
карарына  2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлегендә, якын туганнары, хатыны(ире), законлы вәкиле булмаган вафат булганнарны күмү буенча хезмәт күрсәтүләрнең 2024 елга гарантияләнгән исемлеге бәясе**

| **Т/с** | **Хезмәт күрсәтүнең атамасы** | **Хезмәт күрсәтүнең бәясе *(сум)*** |
|---|---|---|
| 1. | Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. | Тәнне төрү | 644,69 |
| 3. | Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3230,42 |
| 4. | Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 792,47 |
| 5. | Күмү (кабер казу һәм җирләү) | 3702,62 |
| | **Барлыгы** | **8370,20** |